СОВЕТ ПОДГОРНО-БАЙЛАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАУАСТЫ БАЙЛАР
АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Балар авыл җирлегенең Дәвек торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**18 ноябрь 2024 ел** **№ 5**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пунктында гражданнар жыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1.«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Дәвек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан,көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизациялэнгэннэрдэн һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Дәвек т. п. зиратында агач кисү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы жирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Дәвек т. п. 3 нче

тыкрыгындагы юлга вак таш сатып алу һәм салу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Дәвек торак пунктында кышкы чорда юлларны грейдерлау (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

3.Әлеге карарны Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга(http://menzelinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы ____________ З.С.Гәрәева